**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 17 март № 144

г. Казань

«Казан мәгълүмат технологияләре һәм элемтә техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесен төзү турында

«Автоном учреждениеләр турында» 2006 елның 3 ноябрендәге 174-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, квалификацияле эшчеләрне һәм белгечләрне әзерләү сыйфатын күтәрү, белем бирү процессына эш бирүчеләр йогынтысын көчәйтү һәм хезмәт ресурсларын тагы да нәтиҗәлерәк файдалану максатларында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 ел, 23 май, 497 нче карары белән расланган 2016 – 2020 елларга мәгарифне үстерү федераль максатчан программасы чараларын тормышка ашыру кысаларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгының гамәлдә булган «Казан мәгълүмат технологияләре һәм элемтә техникумы» дәүләт бюджет һөнәри белем бирү учреждениесенең төрен үзгәртү юлы белән «Казан мәгълүмат технологияләре һәм элемтә техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесен (алга таба – автоном учреждение) төзү турында тәкъдимен кабул итәргә.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

автоном учреждениене гамәлгә куючы вазыйфаларын һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы башкара;

урта һөнәри белемнең төп һөнәри белем бирү программаларын тормышка ашыру автоном учреждение эшчәнлегенең максаты булып тора.

3. Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына:

60 көн эчендә бюджет учреждениесе Уставындагы тиешле үзгәрешләрне расларга;

бюджет учреждениесе Уставына кертелә торган үзгәрешләрне дәүләт теркәвенә алган көннән соң 30 көн эчендә автоном учреждениенең күзәтүчеләр советы составын расларга;

бюджет учреждениесе Уставына кертелә торган үзгәрешләрне дәүләт теркәвенә алганнан соң җиде көн эчендә оператив идарә хокукында дәүләт мөлкәтен беркетү өчен кирәкле документларны, шул исәптән күчемсез милек объектларына техник документларны, шулай ук җир кишәрлеген рәсмиләштерү өчен кирәкле документларны автоном учреждение тарафыннан Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына тапшыруны тәэмин итәргә;

ел саен автоном учреждение өчен аның Уставында каралган төп эшчәнлеге нигезендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен билгеләнгән тәртиптә расларга.

4. Автоном учреждение Уставын дәүләт теркәвенә алганнан соң Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына:

30 көн эчендә оператив идарә хокукында Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен, шул исәптән элек бюджет учреждениесенә беркетелгән булган, 420061, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Галиев урамы, 3а йорт; 420061, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Галиев урамы, 3 йорт адреслары буенча урнашкан автоном учреждение эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле аеруча кыйммәтле мөлкәтне автоном учреждениегә беркетергә;

дүрт ай эчендә әлеге пунктның икенче абзацы нигезендә автоном учреждениегә беркетелергә тиеш күчемсез милек объектлары урнашкан җир кишәрлекләрен автоном учреждениегә даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга бирүне тәэмин итәргә.

5. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына тиешле финанс елына һәм планлаштырылган чорга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары буенча бюджет исемлегенә тиешле үзгәрешләр кертергә.

6. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы белән берлектә, бюджет учреждениесе Уставына кертелгән үзгәрешләр дәүләт теркәвенә алынганнан соң 30 көн эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 елга урта звено белгечләрен әзерләү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнарны һәм Татарстан Республикасының дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларын торак урыннар белән тәэмин итүгә нормативлар чыгымнарны раслау турында» 2015 ел, 16 октябрь, 776 нчы карарына бюджет учреждениесе исемен бу карарның 1 нче пунктына яраклаштыру өлешендә үзгәрешләр кертү хакында карар проектын эшләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каравына кертергә.

7. Автоном учреждение тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанс ягыннан тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм дәүләт йөкләмәсе үтәлешен финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2015 ел, 31 декабрь, 1044 нче карары нигезендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

8. Автоном учреждениене Мәгълүмати һәм коммуникацион технологияләр өлкәсендә төбәкара үзәк итеп билгеләргә.

9. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2016\144.docx